ГЛАВА
КУГАРЧИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422662, с. Кугарчино,
ул. Советская, дом 65а

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
КҮГӘРЧЕН АВЫЛ
ЖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

422662, Күгәрчен авылы,
Совет урамы, 65а йорт

Тел.: (84361) 20-489, эл.адрес: Kugar.Rs@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

от 07.11.2024 года с. Кугарчино № 1

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күгәрчен авыл жирлегенең Күгәрчен авыл торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендәге ”Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 45-ЗРТ номерлы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “ Күгәрчен авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 22 маддәсе нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күгәрчен авыл җирлегенең Күгәрчен һәм Зәңгәр-Күл авыл торак пунктында үзара салым кертү буенча гражданнар җыенын 2024 елның 19 ноябрендә 14 сәг. 00 минутка билгеләргә.

2.Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

Сез 2025 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күгәрчен авыл җирлегенең Күгәрчен һәм Зәңгәр-Күл авыл торак пунктларында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, балачактан инвалидлардан, беренче төркем инвалидларыннан , бөтенләй ялгыз яшәүче 80 яшькә җиткән пенсионерлардан һәм мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала , аларның саны җирлектә яшәүчеләрнең гомуми саныннан 30 проценттан артып китә алмый, 500 сум күләмендә үзара салым акчасы кертүгә һәм тупланган средстволарны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге

автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
- су белән тәэмин итү системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су җыя торган башка инженер корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау, аларны чистарту, су белән тәэмин итү һәм халыкка су бирү;
- торак пункт территориясен төзекләндерү.

ЯКЛЫЙМ" "КАРШЫ"

3. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күгәрчен авыл җирлегенең Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Күгәрчен авылы, Зәит урамы, 1 А йорт; адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"ында урнаштырырга.

4. Карар басылып чыккан (халыкка белдерелгән) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Күгәрчен авыл җирлеге башлыгы: А.Т.Сафин